**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2893**
**08.05.2024**

Мәктәп укучылары арасында шәһәр
конкурслары үткәрү турында

Тәрбия процессын тормышка ашыруның сыйфатын күтәрү, шәһәр балаларының һәм яшүсмерләренең иҗади һәм лидерлык сыйфатларын үстерү максатында, Башкарма комитетның 2022 елның 3 октябрендәге 5185 номерлы Карары белән расланган «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәренең мәгариф системасын үстерү» муниципаль программасын үтәү йөзеннән

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның мәгариф идарәсенә 2024 елда мәктәп укучылары арасында шәһәр конкурслары үткәрергә.

2. Расларга:

1) «Тату сыйныф серләре» ата-аналар комитетлары республика конкурсының муниципаль этабы турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) «Игелек кылырга ашыгыгыз!» тимурчылык отрядларының шәһәр конкурсы турында нигезләмәне, 2 нче кушымтада каралганча;

3) балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны профилактикалау отрядларының шәһәр конкурсы турында нигезләмәне, 3 нче кушымтада каралганча;

4) «Яр Чаллы шәһәре 1 нче Постының иң яхшы часовое» шәһәр конкурсы турында нигезләмәне, 4 нче кушымтада каралганча;

5) «Җырчы Чаллы» шәһәр конкурсы турында нигезләмәне, 5 нче кушымтада каралганча;

6) рус һәм татар телләрендә КВН мәктәп лигасы уеннарын үткәрү турында нигезләмәне, 6 нчы кушымтада каралганча;

7) мәктәп укучылары арасында шәһәр конкурсларын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 7 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә мәктәп укучылары арасында шәһәр конкурслары үткәрүгә чыгымнарны финанслауны 2024 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Мәгариф өлкәсендә башка мәсьәләләр» 0709 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына, 8 нче кушымтада каралганча 1 680 000,00 (бер миллион алты йөз сиксән мең) сум 00 тиен күләмендә тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы Р.Н. Хуҗинга, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                                    Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2024 елның 8 маендагы
2893 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Тату сыйныф серләре»
ата-аналар комитетлары республика
конкурсының муниципаль этабы турында
нигезләмә

## 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. «Тату сыйныф серләре» ата-аналар комитетлары республика конкурсы (алга таба - конкурс) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм «Гаиләгә социаль ярдәм күрсәтү һәм гаилә кыйммәтләрен саклау илкүләм ата-аналар ассоциациясе» гомумроссия иҗтимагый оешмасы инициативасы буенча үткәрелә.

Конкурсның муниципаль этабы Башкарма комитетның 2023/2024 елларга мәгариф идарәсе планы нигезендә үткәрелә һәм «1 нче шәһәр балалар һәм яшьләр иҗаты сарае» МАӨББУ, «14 нче балалар-яшүсмерләр үзәге» МАӨББУ, «Огниво» 16 нчы балалар иҗат үзәге» МАӨББУ тарафыннан оештырыла.

2. Конкурсның максаты булып мәктәп укучыларын тәрбияләүдә белем бирү оешмалары һәм ата-аналар комитетларының үзара хезмәттәшлегенең иң яхшы практикаларын ачыклау һәм популярлаштыру тора.

3. Конкурсның бурычлары:

1) белем бирү оешмасы белән идарә итүдә актив катнаша торган ата-аналар комитетларын ачыклау;

2) ата-аналарның инициативаларын стимуллаштыру һәм аларга ярдәм күрсәтү, укучыларны тәрбияләүдә гаилә һәм мәктәпнең үзара мөнәсәбәтләрен популярлаштыру.

## 2 бүлек. Конкурсны оештыру

4. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен, составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә.

5. Конкурста Яр Чаллы шәһәренең белем бирү оешмалары 5-11 сыйныфларының ата-аналар комитетлары катнаша ала. Команда составы сәхнәдә берьюлы 12 кешедән артырга тиеш түгел.

## 3 бүлек. Конкурсны үткәрү тәртибе

6. Конкурс өч этапта үткәрелә:

1) мәктәп этабы;

2) район этабы;

3) финал этабы.

7. Конкурс биремнәре:

1) ирекле формада «Безнең күңелле, тату сыйныф!» визит карточкасы. Чыгышның регламенты 5 минутка кадәр.

Бәяләү критерийлары (максималь балл – 20):

- иҗат идеясе - 5 балл;
- артистлык - 5 балл;
- оригинальлек - 5 балл;
- бердәмлек - 5 балл;

2) «Тату сыйныф серләре» күргәзмәсе фотоальбом, стенгазеталар, плакатлар, күмәк иҗади проектлар, портфолио һәм башкаларны үз эченә ала;

3) «Педагог һәм остаз – өйрәтергә һәм өйрәнергә» иҗат номеры. Чыгышның регламенты 5 минутка кадәр.

Бәяләү критерийлары (максималь балл – 20):

- иҗат идеясе - 5 балл;
- артистлык - 5 балл;
- оригинальлек - 5 балл;
- бердәмлек - 5 балл;

4) «Халык мәдәнияте һәм традицияләре» иҗади проектын яклау. Иҗади проектны яклауга 7 минут вакыт бирелә.

Иҗади проект балаларны театрларга, музейларга, китапханәләргә йөрүгә, дөнья һәм матур әдәбиятны, архитектураны, сынлы һәм музыка сәнгатен өйрәнүгә җәлеп итүгә юнәлдерелгән булырга тиеш.

Бәяләү критерийлары (максималь балл – 20):

- иҗат идеясе - 5 балл;
- артистлык - 5 балл;
- оригинальлек - 5 балл;
- бердәмлек - 5 балл.

## 4 бүлек. Конкурста катнашуга заявка

8. Заявка Автозавод, Комсомол, Үзәк районнары буенча конкурс үткәрү өчен җаваплыларның электрон адресларына җибәрелә:

- «1 нче шәһәр балалар һәм яшьләр иҗаты сарае» МАӨББУ, gcdt1_chelny@mail.ru (Автозавод районы);
- «Огниво» 16 нчы балалар иҗат үзәге» МАӨББУ, ognivo_chelny@mail.ru (Комсомол районы);
- «14 нче балалар-яшүсмерләр үзәге» МАӨББУ, dyc_chelny@mail.ru (Үзәк районы).

## 5 бүлек. Конкурска йомгак ясау

9. Конкурска йомгак оештыру комитеты тарафыннан ясала, карар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

10. Финал этабы йомгаклары буенча иң күп балл җыйган конкурста катнашучы (ата-аналар комитеты) конкурсның республика этабына үтә.

11. Конкурсның район этабында катнашучыларның барысына да катнашучы сертификатлары тапшырыла.

12. Муниципаль финал этабында җиңүче Алабуга шәһәренә сәфәр белән бүләкләнә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2024 елның 8 маендагы
2893 номерлы карарына
2 нче кушымта

«Игелек кылырга ашыгыгыз!»
тимурчылык отрядларының шәһәр конкурсы турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә «Игелек кылырга ашыгыгыз!» тимурчылык отрядлары шәһәр конкурсының (алга таба - конкурс) максатларын, бурычларын, үткәрү тәртибен һәм срокларын билгели.

2. Конкурс Башкарма комитетның мәгариф идарәсе инициативасы буенча Яр Чаллы шәһәренең «1 нче шәһәр балалар һәм яшьләр иҗаты сарае» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан үткәрелә.

3. Конкурсның максаты булып Яр Чаллы шәһәрендә тимурчылык хәрәкәтен үстерүгә ярдәм күрсәтү өчен шартлар тудыру, җәмгыятькә иректе рәвештә хезмәт иткән өчен тимурчылык отрядларына иҗтимагый хөрмәт һәм рәхмәт белдерү тора.

4. Конкурсның бурычлары булып тора:

1) мәктәп укучыларының гражданлык инициативасын һәм гражданлык җаваплылыгын үстерү;

2) тимурчылык эшчәнлегенең нәтиҗәле эшләүче программалары, технологияләре, ысуллары практикасының иң яхшыларын ачыклау һәм аларга булышлык итү, уку елы йомгаклары буенча иң яхшы тимурчылык отрядларын бүләкләү.

2 бүлек. Конкурсны оештыру

5. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен, составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә.

6. Конкурста 2023 елның сентябреннән 2024 елның мартына кадәр (кертеп) эшчәнлек нәтиҗәләре буенча рейтинг таблицасында иң күп балл җыйган шәһәрнең гомуми белем бирү оешмаларының тугыз тимурчылык отряды катнаша.

7. Отрядта катнашучылар саны 15 кеше.

3 бүлек. Конкурсны үткәрү тәртибе

8. Конкурс 3 турда уза:

беренче тур – отряд эшчәнлеген яклау;

икенче тур – «Проект конвейеры» эшлекле уены;

өченче тур – «Тимурчылык отряды тормышыннан бер ел» эшлекле уены.

9. Отряд эшчәнлеген яклаганда, конкурста катнашучылар агымдагы уку елының сентябреннән отряд эшчәнлеге тәҗрибәсен һәм нәтиҗәләрен тәкъдим итәләр.

Бәяләү критерийлары (максималь балл – 25):

1) чыгышның мәгънәви эчтәлеге – 10 балл;

2) эшчәнлеккә анализ, тимурчылык отряды эшендә технологияләр, инновацион ысуллар һәм алымнар куллану – 10 балл;

3) ораторлык осталыгы – 5 балл.

Чыгыш мультимедиа презентациясе белән алып барыла. Регламент - 5 минут.

10. «Проект конвейеры» эшлекле уены. Тимурчылык отрядында катнашучыларның социаль проектны эшләүнең һәр адымын күрсәтү һәм аны презентацияләү буенча мөстәкыйль (педагог катнашыннан тыш) эшен чагылдыра. Эшлекле уенда һәр командадан биш кешелек составтагы делегация катнаша. Үткәрү регламенты 1 сәгать 20 минут.

Бәяләү критерийлары (максималь балл – 30):

1) проект культурасына ия булу, проект структурасын белү – 5 балл;

2) максат кую (максат һәм бурычларны формалаштыра белү) – 5 балл;

3) проблеманың куелышы – 5 балл;

4) ресурслар белән тәэмин итү - 5 балл;

5) эш механизмнарының креативлыгы – 5 балл;

6) проектны презентацияләү – 5 балл.

11. «Тимурчылык отряды тормышыннан бер ел» эшлекле уены командаларга бирелгән алгоритм буенча отряд эшчәнлеген модельләштерергә тәкъдим ителә торган уенны чагылдыра. Эшлекле уенда һәр командадан биш кешелек составтагы делегация катнаша. Үткәрү регламенты 1 сәгать 20 минут.

Бәяләү критерийлары (максималь балл - 20 балл):

1) тәкъдим ителгән эшләр саны – 5 балл;

2) тәкъдим ителә торган чараларның креативлыгы һәм яңалыгы – 10 балл;

3) командада эшли белү, коммуникатив күнекмәләр – 5 балл.

## 4 бүлек. Конкурска йомгак ясау

12. Конкурска йомгак оештыру комитеты тарафыннан ясала, карар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

13. Конкурсның финалы «1 нче шәһәр балалар һәм яшьләр иҗаты сарае» МАӨББУда була. Конкурс турлары йомгаклары буенча рейтинг таблицасында максималь балл җыйган 8 отряд финалда катнашучылар булып тора.

14. 1 нче, 2 нче, 3 нче урыннарны алган өч команда сертификатлар һәм дипломнар белән бүләкләнә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2024 елның 8 маендагы
2893 номерлы карарына
3 нче кушымта

Балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны
профилактикалау отрядларының шәһәр конкурсы турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны профилактикалау отрядларының шәһәр конкурсы (алга таба - конкурс) мәктәп мохитендә балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны превентив профилактикалауга юнәлдерелгән. Башкарма комитетның мәгариф идарәсе инициативасы буенча үткәрелә һәм Яр Чаллы шәһәренең «1 нче шәһәр балалар һәм яшьләр иҗаты сарае» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан оештырыла.

2. Конкурсның төп максаты булып Яр Чаллы шәһәре балалары һәм яшьләре арасында хокук саклау хәрәкәтен популярлаштыру һәм үстерү, хокукый тәрбия нигезләрен һәм үзаңны ныгыту тора.

3. Конкурсның бурычлары булып тора:

1) шәһәрнең гомуми белем бирү оешмаларында хокук саклау хәрәкәтен үстерүне стимуллаштыру;

2) хокук бозуларны профилактикалау (алга таба – ХБП) отрядларының эшен оештыруда тәҗрибә алмашу;

3) шәһәрнең гомуми белем бирү оешмаларында иң яхшы ХБП отрядларын ачыклау.

2 бүлек. Конкурсны оештыру

4. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен, составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә.

5. Конкурста катнашуга, Башкарма комитетның район хакимиятләренә заявка биргән шәһәр гомуми белем бирү оешмаларының 11 кешелек составтагы ХБП отрядлары кертелә.

3 бүлек. Конкурсны үткәрү тәртибе

6. Конкурс 3 этапта үткәрелә:

1) портфолио яклау;

2) ХБП отряды эшчәнлеген яклау – ярымфинал;

3) конкурсның финалы.

7. Конкурсның беренче этабы Башкарма комитетның районнар хакимиятендә читтән торып үткәрелә һәм ХБП отряды эшчәнлегенең портфолиосын тәкъдим итүне үз эченә ала.

8. Портфолио түбәндәгеләрне чагылдырырга тиеш:

1) отрядның үсеш этаплары;

2) 2-3 еллык эшкә анализ, йомгаклар, нәтиҗәләлек;

3) дәресләрне оештыруның яңа технологияләре, формалары;

4) фотосурәтләр белән педагог турында, отряд турында мәгълүмат;

5) чара турында кыскача белешмә белән иң яхшы чараларның фотоиллюстрацияләре.

9. Портфолионың титул бите түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

1) гомуми белем бирү оешмасының исеме;

2) ХБП отряды җитәкчесенең Ф.И.А.и.;

3) ХБП отрядының исеме;

4) шәһәр, бастырып чыгару елы.

10. Портфолио критерийлары:

1) максатка һәм бурычларга туры килү – 10 балл;

2) компактлы, логикага нигезләнгән һәм мәгълүматка бай булу – 10 балл;

3) ведомствоара үзара эшчәнлекне чагылдыру, бердәм эш нәтиҗәлелеге – 10 балл;

4) отряд атрибутикасы булу – 5 балл;

5) төсләргә бай булу һәм креативлык – 5 балл;

6) отряд эшен чагылдыра торган фоторәсемнәр булу – 5 балл;

7) шәһәр программаларында, акцияләрдә катнашу – 10 балл.

11. Оештыру комитеты тапшырылган материалларны бәяли. Аларны бәяләү йомгаклары буенча һәр районнан гомуми белем бирү оешмаларының конкурс ярымфиналына чыга торган 5 иң яхшы ХБП отряды билгеләнә.

12. Конкурсның икенче этабы (ярымфинал) ХБП отрядының сафта йөрүгә әзерлек смотрын һәм сугыш турында җыр инсценировкасын үз эченә ала.

13. Отрядларның сафта йөрү смотрын бәяләү критерийлары:

1) команда бирүнең төгәллеге - 5 балл;

2) отряд тарафыннан командаларны синхронлы үтәү - 5 балл;

3) тышкы кыяфәт (кием формасы, баш киеме, шевроннар булу, пөхтәлек) - 5 балл.

14. Сугыш турында җыр инсценировкасын бәяләү критерийлары:

1) чыгышның конкурс тематикасына туры килүе - 3 балл;

2) җырның характерын һәм төп мәгънәсен күрсәтә белү - 5 балл;

3) инсценировканың сәнгатьлелеге һәм эмоциональлеге - 5 балл;

4) артистлык - 5 балл;

5) номерның тулылыгы һәм аның композицион бердәмлеге - 5 балл;

6) башкару сыйфаты - 5 балл;

7) тышкы кыяфәт, сәхнә костюмнары һәм реквизитлар куллану - 3 балл.

15. Оештыру комитеты сафта йөрү смотрын һәм инсценировканы бәяли һәм конкурс финалында катнашу өчен 6 иң яхшы ХБП отрядын билгели.

16. Өченче этап (финал) түбәндәге конкурс сынауларын үз эченә ала:

1) визитка;

2) интеллектуаль конкурс;

3) командирлар конкурсы;

4) «җанатарлар» конкурсы.

17. «Отряд визиткасы».

Команда иҗади формада ХБП отряды эшчәнлеге белән таныштыра. Чыгыш барышында видеофильмнар, интервью фрагментлары файдаланылырга, җырлар башкарылырга мөмкин.

Бәяләү критерийлары:

1) иҗади якын килү һәм оригинальлек - 10 балл;

2) сөйләм һәм үз-үзеңне тоту культурасы - 5 балл;

3) музыка ярдәмендә башкару, техник чаралардан файдалану - 5 балл;

4) теманы ачу тулылыгы (ХБП отрядының эшчәнлеге) - 10 балл;

5) тышкы кыяфәт - 5 балл.

18. «Хокук белеме нигезләре» интеллектуаль конкурсы.

Сораулар мәктәп программасы нигезендә төзелгән. Бөтен команда катнаша. Дөрес җаваплар һәм башкарылган биремнәр өчен командаларга баллар өстәлә. Һәр дөрес җавап 1 баллга туры килә.

19. ХБП отрядлары командирларының конкурсы.

ХБП отрядлары командирларына отряд эшчәнлеге кысаларында әлеге уку елында тормышка ашырыла торган социаль проектны тәкъдим итәргә кирәк.

Бәяләү критерийлары:

1) материалны тәкъдим итү сыйфаты (презентация булу) - 5 балл;

2) социаль проектның эчтәлеге (актуальлек, реалистик булу) - 10 балл;

3) сөйләм һәм үз-үзеңне тоту культурасы - 5 балл;

4) конструктив диалог алып бару (оештыру комитеты әгъзаларының сорауларына нигезле җавап бирә белү) - 5 балл.

20. «Җанатарлар» конкурсы.

Конкурс сынаулары процессында оештыру комитеты әгъзалары җанатарларның активлыгын бәяли.

Җанатарларны бәяләү критерийлары:

1) җанатарлар саны - 5 балл;

2) командага ярдәм итү өчен бердәм стиль һәм атрибутика (футболкалар, плакатлар, маракаслар, речевкалар һ. б.) булу - 5 балл;

3) сөйләм һәм үз-үзеңне тоту культурасы - 5 балл.

## 4 бүлек. Конкурска йомгак ясау

21. Конкурска йомгакны конкурс финалында оештыру комитеты ясый, карар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

22. Конкурсның җиңүчеләре булып конкурсның бәяләү критерийлары нигезендә иң күп балл җыйган 3 отряд тора.

23. Конкурс җиңүчеләре һәм призерлары дипломнар белән бүләкләнә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2024 елның 8 маендагы
2893 номерлы карарына
4 нче кушымта

«Яр Чаллы шәһәре 1 нче Постының иң яхшы часовое»
шәһәр конкурсы турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге нигезләмә «Яр Чаллы шәһәре 1 нче Постының иң яхшы часовое» шәһәр конкурсының (алга таба - конкурс) максатларын, бурычларын, үткәрү тәртибен һәм срокларын билгели.

2. Конкурс ел саен Башкарма комитетның мәгариф идарәсе инициативасы буенча Яр Чаллы шәһәренең «1 нче шәһәр балалар һәм яшьләр иҗаты сарае» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан үткәрелә.

3. Конкурсның төп максаты булып Мәңгелек ут янында мемориаль Хәтер Вахтасында (алга таба – 1 нче Пост) хезмәт итүдә аерылып торган Яр Чаллы шәһәренең муниципаль белем бирү оешмалары балалары һәм яшьләре арасында гражданлык-патриотик хәрәкәтне популярлаштыру һәм үстерү тора.

4. Конкурсның бурычлары булып тора:

1) укучыларның гражданлык-патриотик тәрбия үсешен стимуллаштыру;

2) 1 нче Постта хезмәт итү тәҗрибәсен пропагандалау;

3) 1 нче Постның иң яхшы часовойларын ачыклау.

2 бүлек. Конкурсны оештыру

5. Конкурсны оештыру һәм үткәрүне составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты гамәлгә ашыра.

6. Конкурста Яр Чаллы шәһәре муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының 8-11 сыйныф укучылары катнаша.

3 бүлек. Конкурсны үткәрү тәртибе

7. Конкурс нәтиҗәләре мемориаль атна йомгаклары нигезендә түбәндәге критерийлар буенча чыгарыла:

1) 1 нче Постта үз-үзен тотуга характеристика (5 балл):

- дисциплина бозу очраклары булу (0 балл);
- дисциплина бозу очраклары булмау (5 балл).

2) 1 нче Постта үткәрелгән чараларда катнашу (5 балл):

- чаралар оештыруда катнашу (3 балл);
- чарада бары тик катнашу (2 балл).

3) «Бөек Ватан сугышы тарихы» һәм «Яр Чаллы шәһәре Бөек Ватан сугышы елларында» темалары буенча белемнәре (5 балл):

- өйрәнелгән темалар буенча белемнәре булу (5 балл);
- әлеге темалар буенча белемнәре булмау (0 балл).

4) сафта йөрү әзерлеге күнекмәләрен белү (15 балл):

- сафта йөрү (поход) адымы белән хәрәкәт итү (5 балл);

- «Тигезлән» («Равняйсь»), «Үрә кат» («Смирно»), «Уртага тигезләнү» («Равнение на середину») командаларын башкару, борылулар (уңга, сулга, үз тирәндә) (5 балл);
- хәрби сәламләү башкару: урында, хәрәкәт иткәндә, баш киемендә (5 балл).

5) «Минем тормышымда 1 нче Постның роле» темасына инша язу (5 балл).

4 бүлек. Конкурска йомгак ясау

8. Оештыру комитеты конкурс үткәрүгә йомгак ясый, шулай ук 1 нче, 2 нче, 3 нче урыннарны алган конкурс җиңүчеләрен һәм призерларын билгели. Оештыру комитеты карары беркетмә белән рәсмиләштерелә.

9. Конкурс җиңүчеләренә «Яр Чаллы шәһәре 1 нче Постның иң яхшы часовое» исеме бирелә. Иң күп балл җыйган 20 кеше Мәскәү шәһәренә Кремльнең Президент Полкы белән очрашуга бару белән бүләкләнәләр.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2024 елның 8 маендагы
2893 номерлы карарына
5 нче кушымта

«Җырчы Чаллы» шәһәр конкурсы турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Гомуми белем бирү оешмалары арасында «Җырчы Чаллы» хор музыкасы шәһәр конкурсы Башкарма комитетның мәгариф идарәсе инициативасы буенча Яр Чаллы шәһәренең «7 нче балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан үткәрелә.

2. Конкурсның төп максатлары булып хор сәнгате традицияләрен популярлаштыру һәм үстерү; гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучыларның иҗади потенциалын ачыклау һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә иҗади ярышларга җәлеп итү.

3. Конкурсның бурычлары булып тора:

1) үсеп килүче буынны рухи-әхлакый тәрбияләүдә балалар хор иҗатының ролен арттыру;

2) талантлы балаларга иҗади потенциалларын тормышка ашыруда ярдәм итү, яшь талантларның алга таба иҗади үсешен стимуллаштыру;

3) балаларның хор иҗатына кызыксынуын актуальләштерү;

4) коллективлар репертуарының сәнгать дәрәҗәсен һәм башкару осталыгын арттыру;

5) балаларда патриотизм, туган телгә мәхәббәт, туган илгә мәхәббәт хисләре тәрбияләү;

6) коллективлар репертуарының сәнгать дәрәҗәсен һәм башкару осталыгын арттыру;

7) укучыларның актив тормыш позициясен раслау;

8) шәһәрнең иң яхшы балалар хор коллективлары белән иҗади аралашу

2 бүлек. Конкурсны оештыру

4. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен, составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә. Оештыру комитеты түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

1) конкурста катнашучылардан заявкалар кабул итә;

2) составына шәһәрнең танылган хормейстерлары һәм музыкантлары кергән конкурсның жюри составын формалаштыра;

3) конкурста катнашучылар исемлеген раслый;

4) Гала-концерт үткәрү көнен билгели.

5. Конкурста оештыру комитетына заявка биргән гомуми белем бирү оешмаларының хор коллективлары катнаша.

3 бүлек. Конкурсны үткәрү тәртибе

6. Конкурс өч этапта үткәрелә:

- 1 этап – мәктәп этабы;
- 2 этап – муниципаль;
- 3 этап – иң яхшы хор коллективлары катнашында Гала-концерт.

7. Катнашучыларның яшь төркемнәре:
- кече төркем – 7 яшьтән 9 яшькә кадәр;
- урта төркем – 10 яшьтән 12 яшькә кадәр;
- өлкән төркем – 13 яшьтән 18 яшькә кадәр.

8. Конкурс чыгышының программасы төрле характердагы 2 әсәрдән торырга тиеш. Рус, чит ил, ватан классикасы әсәрләрен, халык җырын яки яңартылган халык җырын кертергә киңәш ителә.

9. Урта һәм өлкән төркемдә бер a cappella әсәре башкару сорала. Хор башкаруы ике тавыштан да ким түгел.

Барлык яшь төркемнәрендә дә «+» фонограммасына җырларга рөхсәт ителми.

10. Конкурс программасын бәяләү критерийлары:
1) башкару осталыгы, интонация чисталыгы (5 балл);
2) музыкаль әсәрнең музыкальлеге, сәнгать трактовкасы (5 балл);
3) репертуарның катлаулылыгы, конкурс программасының катнашучылар яшенә туры килүе;
4) башкару оригинальлеге (5 балл);
5) башкаруда иҗади якын килү һәм креативлык (5 балл);
6) сәхнә культурасы (5 балл);
7) сәхнә костюмы (5 балл).

Гала-концертта катнашу өчен барлык хор коллективларына түбәндәге әсәрләрне әзерләргә кирәк:
1) Р. М. Яхин «Татарстан Гимны»;
2) М. А. Александров, С. В. Михалков «Россия Гимны»;
3) И.М. Лученок, М. Ясень «Май вальсы».

## 4 бүлек. Конкурс йомгаклары

11. Конкурс йомгаклары жюри составы тарафыннан ясала, карар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

12. Конкурсның җиңүчесе булып, конкурс программасын бәяләү критерийлары нигезендә иң күп балл җыйган хор коллективы тора.

13. Җиңүчегә «Гран-При лауреаты» исеме бирелә, коллектив Алабуга шәһәренә сәфәр белән бүләкләнә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2024 елның 8 маендагы
2893 номерлы карарына
6 нчы кушымта

Рус һәм татар телләрендә
КВН мәктәп лигасы уеннарын үткәрү турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. КВН мәктәп лигасы уеннары (алга таба — Лига) Башкарма комитетның мәгариф идарәсе инициативасы буенча Яр Чаллы шәһәренең «14 нче балалар-яшүсмерләр үзәге» муниципаль автономияле өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан үткәрелә.

2. Уеннарның максаты:

Яшьләрнең әхлакый, мәдәни казанышларын саклауга һәм арттыруга, актив гражданлык позициясен формалаштыруга ярдәм итү.

3. Бурычлар:

1) өлкән сыйныф укучыларының иҗади эшчәнлегенең төрле төрләрен һәм юнәлешләрен популярлаштыру;

2) талантлы яшьләрне ачыклау һәм аның иҗади потенциалын тормышка ашыру өчен шартлар тудыру;

3) яшьләрдә милли үзаң, үз халкының мәдәни һәм тарихи мирасына карата хөрмәт һәм сакчыл мөнәсәбәт булдыру, туган телгә һәм татар халкы традияләренә мәхәббәт тәрбияләү;

4) КВН яшьләр Лигасын үткәрү традицияләрен саклап калу һәм арттыру;

5) яшьләрне иҗат коллективларына җәлеп итү юлы белән алар арасындагы хокук бозуларны профилактикалау.

2 бүлек. Уеннарны оештыру

4. Уеннарны оештыру һәм үткәрү өчен, составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә.

5. Лиганың оештыру комитеты реклама кампаниясен, техник тәэмин ителешле концерт мәйданчыгын, хезмәт күрсәтүче персонал һәм сак белән, Лига чараларында катнашучы командаларга редактор һәм административ ярдәм күрсәтүне тәэмин итә, репетиция вакытын бирә.

6. Оештыру комитеты жюри составын раслый.

Жюри Лига хокукына ия:

1) уеннарда чыгыш ясаучы командаларның составын билгеләргә;

2) конкурс уеннарында катнашучыларның чыгышларын бәяләргә;

3) катнашучыларның чыгышлары нәтиҗәләре буенча конкурс программасы нәтиҗәләрен коллегиаль билгеләргә.

3 бүлек. Бәяләү критерийлары

7. Лига жюрие уеннарны түбәндәге критерийлар буенча бәяли:

1) шаяртулар авторлыгы - (5 балл);

2) программа сценарие: Лига жанрына туры килү, темаларны ачу оригинальлеге, идеянең оригинальлеге, программа режиссурасы (финаллар линейкасын, тавышны, номерны сәхнәгә кую) - (5 балл);

3) сәхнә культурасы һәм эстетикасы (5 балл);

4) номерның әхлакый-этик эчтәлеге (5 балл);

5) программаның вакыт буенча эзлеклелеге (5 балл).

4 бүлек. Уеннар үткәрү тәртибе

8. КВН Лигасында катнашучылар сыйфатында Яр Чаллы шәһәренең гомуми белем бирү оешмалары тарафыннан җибәрелгән командалар һәм иҗади берлекләр (җыелма командалар) булырга мөмкин.

9. Уеннар оештыру комитеты тарафыннан тәкъдим ителгән һәм Лиганың барлык катнашучылары белән килештерелгән система буенча уза.

10. КВН лигасында катнашырга теләгән командаларга язма рәвештә оештыру комиетына dyc_chelny@mail.ru электрон почтасына заявка бирергә кирәк.

Гаризада түбәндәгеләрне күрсәтергә кирәк:

1) команда исеме;

2) юллама бирүче оешма;

3) команда капитанының һәм җитәкчесенең Ф.И.А.и.;

4) элемтә телефоннары (эш, өй, кәрәзле).

5 бүлек. Уен йомгаклары

11. Йомгаклар жюри тарафыннан ясала, карар беркетмә белән рәсмиләштерелә.

12. Бәяләү критерийлары нигезендә иң күп балл җыйган командалар (рус һәм татар телләрендә) җиңүче булалар.

13. Җиңүче команда Алабуга шәһәренә сәфәр белән бүләкләнә. 2 нче, 3 нче урыннарны алган командалар дипломнар белән бүләкләнә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева